КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 13 февраль г.Казань № 83

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән расланган 2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 ноябрь, 1056 нчы; 2021 ел, 23 ноябрь, 1111 нче; 2022 ел, 18 май, 460 нчы; 2022 ел, 29 октябрь, 1151 нче; 2023 ел, 17 февраль, 151 нче; 2023 ел, 20 июль, 870 нче; 2024 ел, 13 февраль, 77 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә 2025 елның 1 мартына кадәр 2024 елга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планының үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә, 2025 елның 25 декабренә кадәр Татарстан Республикасы халкын газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемаларын эшләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин